ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 605-71/кс-2023

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 №10-101/кс карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 ел өчен төзәтмә кертү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга 2024 елга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 №58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2024 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе өчен 2020-2024 елларга эчә торган суга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2019 №10-101/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 №213-70/кс-2020, 17.11.2021, №298-55/кс-2021, 17.11.2022 №572-151/кс-2022 карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф

учреждениесе өчен эчә торган суга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә календарь бүленгән тарифлар билгеләргә.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2019 №10-101/кс карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 605-71/кс-2023
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе өчен эчә торган суга 2020-2024 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Зеленодольск муниципаль районы | | |
| 1 | Казан федераль (Идел буе) университеты" федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 18,22 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 19,12 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 19,12 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 19,82 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 19,82 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 24,11 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 26,60** |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 26,60 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 33,71 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 15,18 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 15,93 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 15,93 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 16,52 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 16,52 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 20,09 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 22,17** |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 22,17 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 28,09 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.
<**> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 № 572-151/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге